**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.08.2016 № 465

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 25 августында теркәлде, № 3488

Татарстан Республикасы пенсионерларының
аерым категорияләрен ташламалы шартларда
шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен
исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
"Татарстан Республикасы пенсионерларының
аерым категорияләрен ташламалы шартларда
шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен
исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында"
16.07.2015 ел, № 473 боерыгы белән расланган
административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

"Инвалидларның хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2014 елның 1 декабрендәге № 419-ФЗ Федераль законның 26 статьясы 4 өлешенең 2 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан **боерык бирәм**:

Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 16.07.2015 ел, № 473 боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.07.2015 ел, № 473 боерыгы белән расланган административ регламентының (алга таба – Регламент) 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Керемнәрне исәпкә алу һәм азкеремле дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен, гаиләнең җан башына керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында” 2003 елның 5 апрелендәге № 44-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 44-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 14, 1257 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында” 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өл.), 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өл.), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Инвалидларның хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 1 декабрендәге № 419-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 49 (VI өл.), 6928 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 2012 елның 7 маендагы № 601 Россия Федерациясе Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Аларга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен, гаиләнең җан башына керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә искә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында” 2003 елның 20 августындагы № 512 карары (алга таба – № 512 карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 34, 3374 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2014 елның 15 декабрендәге “Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында файдаланылучы документларының бердәйләштерелгән формаларын һәм аларны тутыру тәртибен раслау турында” № 834н боерыгы (алга таба – № 834н боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, http://www.pravo.gov.ru, 26.02.2015);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 33,

1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвасы белән тәэмин итүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвасы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында" 14.02.2011 ел, № 97 карары белән расланган тәртибе (алга таба – № 97 ТР МК карары белән расланган Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 11.05.2011, № 18, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).";

Регламентның 2 бүлегенең 2.4 пунктының "Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша документлар сорап алу зарурлыгы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү срогы ун көнгә кадәр озайтыла";

Регламентның 2 бүлегенең 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, | |

| | | |
|---|---|---|
| урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законына туры китереп, әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга карата таләпләр | мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидның дәүләт хезмәте күрсәтү урыннарыннан каршылыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга каршылыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга бару максатыннан, объект эчендә бер урыннан бер урынга мөстәкыйль күчеп йөрү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып"; | |

Регламентның 2 бүлегенең 2.15 пунктының "Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасының дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләрен түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

"инвалидларга аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү";

Регламентның 4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә тикшерүләр үткәрү юлы белән Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне Министрлыкның вазыйфаи затлары башкара. Контрольлек итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык бүлекләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи Регламентларда билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, карарлар кабул итү һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып, тикшерү үткәрү тора:

делопроизводствоны алып баруны;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүне;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүне.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) характерда була.

4.3. Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу тикшерүләр нәтиҗәсендә ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контрольлек итү Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы,

актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.”.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**